**Исполнительный комитет Поручиковского сельского поселения Заинского муниципального района Республики Татарстан**

ул.Горбунова, зд. 2а, с.Поручиково, Заинский район, (индекс) 423520 тел. 3 70 49

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлегенең башкарма комитеты**

Горбунов урамы, 2а номерлы бина, Поручик авылы, Зәй районы, (индекс) 423520 тел. 3 70 49

Телефон, факс 3-70-49. Электронный адрес: Por.Zai@tatar.ru, сайт: www.http://zainsk.tatarstan.ru/poruchikovskoe.htm

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**03.09.2021г.** **№ 24**

**«Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 23.07.2021 номерлы Зәй муниципаль районы 16 авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районының Поручик авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Поручик авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 23.07.2021 елның 16 номерлы Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган административ регламентка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5 пунктта өченче абзацны төшереп калдырырга;

1.2. 2.6 пунктта икенче баганада 2 пунктчаны төшереп калдырырга;

1.3. 2.15 пунктта таблицаның икенче баганасында «мөрәҗәгать итүче тарафыннан алына» сүзләреннән соң «Зәй муниципаль районының рәсми сайтында,» сүзләрен өстәргә;

1.4. 2.16 пунктта икенче баганада «һәм гамәле» сүзләрен «һәм гамәле (гамәл кылмавы)» сүзләре белән алмаштырырга;

1.5. 3.7.1 пунктта «яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.6. 4.1. пунктта:

тиешле килешләрдә «белгечләр» сүзләрен тиешле килешләрдәге «вазыйфаи затлар» сүзләренә алмаштырырга;

1.7. 5 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерүнең судка кадәрге (судтан тыш) тәртибе»;

1.8. 5.1. пунктта:

беренче абзацта «хезмәткәрләрен» сүзен «вазыйфаи затларын» сүзләренә алмаштырырга;

беренче абзацта «башлыгына» сүзен «Башкарма комитет җитәкчесенә» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктчада «Зәй муниципаль районының» сүзләрен «муниципаль хокукый актлар белән» сүзләренә алмаштырырга;

1.9. 5.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Шикаять муниципаль хезмәт күрсәтүче органга язмача кәгазьдә, электрон формада бирелә. Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр югарырак органга (ул булган очракта) бирелә яисә ул булмаган очракта турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан карала.

Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, муниципаль хезмәткәрнең, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Зәй муниципаль районының рәсми сайтыннан (https://zainsk.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланып җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә алынырга мөмкин.»;

1.10. 5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять бирелә торган муниципаль хезмәт күрсәтүче органның аталышы, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәү урыны турында белешмәләр,шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәүне нигезли торган дәлилләре.»

1.11. 5.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.7. әлеге бүлекнең 5.6 пунктында күрсәтелгән шикаять мөрәҗәгать итүчегә җавапта канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне тиз арада бетерү максатында

муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, орган тарафыннан башкарыла торган гамәлләре турында мәгълүматы бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр һәм мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт алу максатында башкарылырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат җиткерелә.»;

1.12. 5.9 пунктта «бирелгән хезмәткәр» сүзләрен «бирелгән» сүзенә алмаштырырга;

1.13. «Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары» кушымтасында «Җитәкче урынбасары» сүзләрен «Сәркатип» сүзенә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **П.В. Тимаськов**